РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 10 2018 г. №753

«2018-2020 елларга Ютазы мунiипаль
районы балаларын һәм яшьләрен патриотик
тәрбияләү турында”гы программаны
раслау турында

«2018-2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү Дәүләт программасы турында»гы 30.12.2015 ел, №1493 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, шулай ук халыкның гражданлык һәм патриотизм дәрәҗәсен күтәрү, патриотик тәрбия бирү системасын камилләштерү, аның эчтәлеген яңарту һәм мәгариф учреждениеләренең көчләрен берләштерү максатларында, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. "2018-2020 елларга Ютазы муниципаль районы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү" муниципаль максатчан программасын (кушымта №1 ) расларга.

2. Ютазы муниципаль районы гражданнарын патриотик тәрбияләү буенча программа чаралары планын (кушымта №2) расларга.

3. Ютазы муниципаль районы гражданнарын патриотик тәрбияләү буенча ведомствоара комиссия составын (кушымта №3) расларга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче С. П. Самонина

А.А. Хисмәтуллин
2-81-97

Кушымта №1
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
карарына
«__» _________ 2018 № ___

# “2018-20120 ЕЛЛАРГА ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЛАЛАРЫН ҺӘМ ЯШЬЛӘРЕН ПАТРИОТИК ТӘРБИЯЛӘҮ” МУНИЦИПАЛЬ МАКСАТЧАН ПРОГРАММАСЫ

## ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | 2018-2020 елларга Ютазы мунииипаль районы балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү муниципаль максатчан программасы |
| **Программаны эшләү өчен нигезләр** | РФ Хөкүмәте карары белән 2015 елның 30 декабрендә №1493 астында расланган “2016-2020 елларга РФ Гражданнарын патриотик тәрбияләү” дәүләт программасы |
| **Программаны төп эшләүче** | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм буенча бүлеге |
| **Программаның төп чараларын башкаручылар (килешү буенча)** | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге,<br>мәгариф бүлеге,<br>башкарма комитетның мәдәният бүлеге,<br>Ютазы районы буенча Татарстан Республикасы хәрби комиссариаты бүлеге,<br>«Халык мәшгульлеге үзәге” ДБУ,<br>Ютазы районы үзәк хастаханәсе,<br>Төбәкне өйрәнү музее,<br>район ветераннар Советы,<br>«Олимп» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе,<br>«Атлант» ЯЯК МБУ<br>“Форпост” җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге МУ,<br>“Ютазы таңы” район газетасы,<br>ДОСААФ РОСТҖ |
| **Программаның максатлары** | Патриотик тәрбия бирү системасын үстерү, ныгыту һәм камилләштерү өчен шартлар тудыру, алга таба Ватанга лаеклы хезмәт итүгә, аны яклауда һәм социаль-икътисадый үсештә катнашуда яшьләрнең гражданлык позициясен һәм ихтыяҗын формалаштыру |
| **Программаның бурычлары** | 1) балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча район массакүләм чаралары системасын үстерүне тәэмин итү;<br>2) гражданнарны оборона өлкәсендә башлангыч белем алу һәм аларны хәрби хезмәт нигезләре буенча укыту сыйфатын күтәрү;<br>3) үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү |

| | |
|---|---|
| | үзәкләре буларак мәгариф учреждениеләрендә патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын яхшырту;<br>4) балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләүнең методик нигезләрен үстерүне, әлеге өлкәдә кадрлар әзерләүне һәм яңадан әзерләүне тәэмин итү;<br>5) патриотик тәрбиянең эчтәлеген, аның методларын, формаларын һәм чараларын яңарту һәм баету;<br>6) мәгълүмат-пропаганда эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, җирле массакүләм мәгълүмат чаралары потенциалын куллану, патриотик тәрбияне үстерүдә мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллану |
| **Программаны гамәлгә ашыру сроклары** | 2018 – 2020 еллар |
| **Программаны гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре** | Программа чаралары түбәндәге юнәлешләр буенча системалаштырыла:<br>патриотик тәрбия процессын камилләштерү;<br>гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү;<br>яшьләрне патриотик рухта тәрбияләү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) эшчәнлеген координацияләү;<br>патриотик тәрбия бирү өлкәсендә мәгълүмати тәэминлек;<br>патриотик тәрбиядә Россия, Татарстан дәүләт символларын һәм Ютазы районы символикасын куллану.<br>Гражданлык-патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү.<br>Гражданлык-патриотик тәрбия бирүнең методик нигезләрен үстерү: Ватан патриотының шәхесен формалаштыру һәм үстерү проблемалары буенча методик тәкъдимнәр эшләү.<br>Гражданлык-патриотик тәрбия бирү өлкәсендәге алдынгы тәҗрибәне мәктәпләр эше практикасына кертү өчен өйрәнү һәм гомумиләштерү.<br>Укучыларның гаиләләрендә гражданлык-патриотик тәрбия бирүдә актив катнашу формаларын үстерү |
| **Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге социаль нәтиҗә көтелә:<br>1. Патриотик аң формалаштыруның, балалар һәм яшьләрнең патриотик хисләр үсешенең уңай динамикасы, мәгариф һәм гомуми мәдәниятнең күтәрелеше, Ютазы районының, Татарстан Республикасының һәм Россиянең тарихи үткәненә карата кызыксынуны арттыру;<br>- дәүләт традицияләрен һәм буыннар арасындагы элемтәләрне саклау, балалар һәм яшьләрнең толерантлыгын арттыру, Татарстан, Россия |

| | |
|---|---|
| | Федерациясе халыкларының бердәмлеген һәм дуслыгын ныгыту;<br>2. Армиягә кадәрге яшьләрдә армия хезмәтенең уңай образын формалаштыру һәм аңа җаваплы караш формалаштыру.<br>3. Мәгариф учреждениеләре җитәкчеләрендә һәм патриотик тәрбия буенча эшне оештыручыларда үсмерләр һәм яшьләр мохитында негатив чагылышларны минмальләштерү буенча һөнәри компетентлыкны күтәрү, җинаятьчелекне киметү, хокук тәртибе һәм куркынычсызлык дәрәҗәсен арттыру<br>4. Патриотик тәрбия процессын оештыруга мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кертүне тәэмин итү. |
| **Программаның нәтиҗәлелеген бәяләү критерийләре** | 1. Балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә юнәлтелгән иҗтимагый әһәмиятле район проектлары һәм программалары саны.<br>2.Үткәрелгән хәрби-спорт уеннары/аларда катнашучылар саны.<br>3. Үткәрелгән хәрби-спорт сборлары/аларда хәзерлек узган яшүсмерләр саны<br>4. Гамәлдәге мәктәп музейлары яки Хәрби дан бүлмәләре саны.<br>5.Патриотик юнәлештәге үткәрелгән күргәзмәләр саны.<br>6.Патриотик тематика буенча үткәрелгән район фестивальләре һәм сәнгать иҗаты конкурслары саны/аларда катнашучылар саны.<br>7. "Хәтер вахтасы»акциясе чаралары саны.<br>8.Өлкәдә муниципаль учреждениеләр эш тәҗрибәсеннән гомумиләштерелгән материаллар саны<br>10.Җирле массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр саны.<br>9. Басылган методик материаллар саны<br>ии. |
| **Программаның үтәлешен контрольдә тоту системасын оештыру** | Әлеге программада катнашучылар муниципаль район башкарма комитетына һәм патриотик тәрбия бирү буенча даими комиссиягә хисап тотарга тиеш. Мәгариф бүлеге, Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге программа чараларын планлаштыру, үзара хезмәттәшлек итү, координацияләү һәм контрольдә тотуны оештыра. |
| **Программаны гамәлгә ашыру механизмы** | Программаны гамәлгә ашыру механизмы ведомствоара кызыксынучы учреждениеләр һәм якларның камилләштерелүенә нигезләнә.<br>Программаны тормышка ашыруга мәгариф учреждениеләре, өстәмә белем бирү учреждениеләре, мәдәният учреждениеләре, укучыларның ата-аналары, иҗтимагый |

| | |
|---|---|
| | оешмалар, предприятиеләр һәм авыл җирлекләре җәлеп ителә. |
| **Ресурс тәэмин ителеше** | Программа Ютазы муниципаль районының җирле бюджеты хисабына финанслана. Иганәчеләр акчаларын җәлеп итү күздә тотыла |

## АКТУАЛЬЛЕК

Хәзерге вакытта балалар һәм яшьләрнең патриотик тойгы-хисләре югалуы сизелә. Хәрби хезмәтнең абруе кимеде.

Һәм, барыннан да элек, җәмгыятьне берләштерү һәм дәүләтне ныгыту нигезе буларак, яшьләрдә патриотизмны тәрбияләү ролен көчәйтү зарурлыгы күзгә күренеп тора. Патриотик тәрбияне яңа эчтәлек белән тулыландыру яңа алымнар нигезендә башкарылырга тиеш.

Туган илгә мәхәббәт, үз илең очен горурлык тәрбияләү бала шәхесен үстерү өчен зур әһәмияткә ия. Ватанга мәхәббәт һәм аның тарихына һәм мәдәниятенә хөрмәттән башка гражданин һәм патриот тәрбияләү, балаларда үз абруйларын, шәхеснең уңай сыйфатларын формалаштыру мөмкин түгел.

Үткәннәрне белмичә, бүгенге дә юк, һәм киләчәк тә була алмый. Чын патриот һәм кеше үз халкының тарихын һәм традицияләрен ныклап белгән вакытта гына була ала. Балалар үзләренең зур ил халкының бер өлеше булуын, үзләренең россиялеләр – татарстанлылар - ютазылылар булуларын тоярга тиеш.

Әлеге идеяне абстракт мисалларда түгел, ә ил, бистә, авыл, мәктәп, гаилә тарихының конкрет материалларында тормышка ашырырга кирәк. Аерым кешеләр язмышы – танылган тарихи шәхесләр, үз гаиләсе әгъзалары, якыннарының һәм ерак туганнарының, бистәбезнең һәм районның күренекле кешеләре, мәктәп укытучылары һәм чыгарылыш укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм «кайнар ноктaларда» хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылар белән танышу аша.

Сугыш ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәре турында кайгырту сүздә түгел, ә эш-гамәлләрдә алып барылырга тиеш. Кораллы Көчләр сафына чакырылыш уңышлы үткәрелә, районда традицион рәвештә «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» булып тора.

Патриотик тәрбияне алга таба камилләштерү, педагогларның тәҗрибәсен баету максатында методик кулланмалар, мастер-класслар, Хәтер, Дан, Батырлык һәм Намуслылык дәресләре эшләү күздә тотыла.

Патриотик тәрбия бирү буенча фестивальләр, конференцияләр, слет – конкурслар үткәрү балаларыбызның кызыксынулары һәм мәнфәгатьләре, аларның әлеге вакыйгаларга, халыкның батырлыгына карата мөнәсәбәтләре турында сөйли. Районда «Ютазы таңы» газетасында, район сайтында сугыш ветераннарының һәм тыл хезмәтчәннәренең батырлыкларын яктыртуның аерым практикасы эшләнде.

Яшьләрнең соңгы еллардагы сайлау кампанияләрендә актив катнашуы билгеләп үтелә. Актив тормыш позициясе һәм илдә барган вакыйгалар өчен шәхси җаваплылык хисе участок сайлау комиссияләре эшендә актив катнашкан яшь гражданнарны характерлый.

Шул ук вакытта патриотик тәрбия системасын нәтиҗәле эшләтү өчен барысы да эшләнмәгән әле. Әхлаклылык, гражданлылык һәм патриотлык җәмгыятьнең тулысынча берләштерә торган нигезенә әверелмәде. Күпчелек очракта ата-аналар, гаилә, коллектив, җәмгыять, Ватан алдында җаваплылык һәм бурычлы булу хисләре җуелды. Боларның барысы да эшне дәвам итү, югары рухи-әхлакый принциплар һәм гражданлык җаваплылыгын тәрбияләүгә, үз Ватанына мәхәббәт һәм тугрылык, җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә әзер булуга, районны үстерү планнарын тормышка ашыруда актив катнашуга юнәлдерелгән проблемаларның бөтен комплексын хәл итү эшенең актуальлеге турында сөйли.

Хәзерге вакытта эшне алга таба камилләштерү, түбәндәгеләргә юнәлдерелгән чаралар үткәрү зарурлыгы туды:

- җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә, районны үстерү планнарын тормышка ашыруда актив катнашуга әзерлек тәрбияләү;

- мәдәни-тарихи кыйммәтләр нигезендә яшьләрнең патриотик хисләрен һәм аңын формалаштыру;

- Ватаныбызның күп гасырлык тарихын, дөнья тарихи процессында Россиянең урынын һәм ролен, илнең бәйсезлеге һәм мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән төрле буыннарның героик үткәнен өйрәнү;

- үз-үзеңне тотуның югары әхлакый һәм этик нормаларын формалаштыру, фидакарьлек, җаваплылык һәм коллективизм, хезмәткә карата ихтирам һәм намуслы мөнәсәбәт формалаштыру;

үсмерләрдә һәм яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, наркоманияне, алкоголизмны, хокук бозуларны һәм күзәтүчесезлекне профилактикалау;

Әлеге программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәле, ведомствоара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк һәм Ютазы муниципаль районында үсеп килүче буынны тәрбияләүдә уңай нәтиҗәләр бирәчәк.

## ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның төп максаты булып патриотик тәрбия системасын камилләштерү, югары патриотик аң формалаштыру, Ватанга тугрылык булдыру, Конституция бурычларын үтәргә әзер булу тора.

Бу максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү зарур:
- патриотик тәрбия системасын булдыруны дәвам итү;
- патриотик тәрбия бирүдә катнашу өчен иҗтимагый оешмаларны, хезмәт коллективларын, аерым гражданнарны күбрәк җәлеп итү;
- мәгариф учреждениеләрендә патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрү, аларны яшь буынга патриотик тәрбия бирү үзәкләренә әверелдерү;
- яшьләрне патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү дәрәҗәсен күтәрү;
- балаларны патриотик тәрбияләүдә гаиләнең ролен арттыру өстендә эшләргә.

Әлеге бурычларны хәл итү Программа чараларын гамәлгә ашыру юлы белән тормышка ашырылачак ***(Кушымта1).***

## ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУНЫҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

Программа чаралары комплексы районның барлык категория гражданнарын патриотик тәрбияләү белән колачлауны күздә тота. Программаның өстенлекле юнәлеше булып үсеп килүче буынга - балалар һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү тора. Шул ук вакытта төп игътибар мәктәп, гаилә, мәдәният, спорт, ММЧ, шулай ук иҗтимагый оешмаларның уртак тәрбия эшчәнлеген интеграцияләүче үзәк буларак мәгариф учреждениеләренә юнәлтелә.

**1. Патриотик тәрбия процессын камилләштерү.**
- хәзерге этапта патриотик тәрбия бирү буенча эшнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү;
- патриотик тәрбия эчтәлеген баету;
- Россия дәүләте, аның казанышлары өчен горурлык хисе тәрбияләү;
- Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлеген мәңгеләштерү;

- җәмгыятькә һәм дәүләткә лаеклы һәм фидакарь хезмәт итүгә, Ватанны саклау бурычларын үтәүгә әзерлек тәрбияләү;
- патриотик тәрбия бирү өлкәсендә белгечләр әзерләү системасын камилләштерү;
- патриотик тәрбия эшендә барлык органнар һәм учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

**2. Хәрби хезмәтнең абруен күтәрү**

- яшьләрне физик һәм психологик яктан әзерләү;
- спортның хәрби-гамәли, спорт-техник төрләрен, ГТО бөтенроссия комплексын популярлаштыру;
- хәрби хезмәткә чакырылучыларның белем дәрәҗәсен күтәрү, алар тарафыннан хәрби-учет белгечлекләре алу;
- гражданнарны хәрби хезмәт нигезләренә өйрәтү.

**3. Патриотик тәрбия бирүнең фәнни-техник һәм методик нигезләрен үстерү**

- патриотик тәрбия бирү өлкәсендә аны патриотик эш практикасына кертү өчен алдынгы тәҗрибәне өйрәнү һәм гомумиләштерү.

**4. Патриотик тәрбия бирү мәнфәгатьләрендә иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеген координацияләү.**

- патриотик тәрбия эшендә иҗтимагый оешмаларның катнашуы өчен шартлар тудыру;
- патриотик тәрбия бирү буенча РОСТО эшен активлаштыру, мәдәният учреждениеләренең, иҗтимагый оешмаларның катнашуын активлаштыру.

**5.Патриотик тәрбия бирү өлкәсен мәгълүмати тәэмин итү**

- массакүләм мәгълүмат чараларының патриотлыкны пропагандалауда тагын да киңрәк катнашулары өчен шартлар тудыру;
- ММЧда патриотик тематиканы киңәйтүгә ярдәм итү һәм булышлык күрсәтү;
- патриотик тәрбия өлкәсендә халыкның иҗади потенциалын үстерүдә булышлык күрсәтү;
- массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәткәрләрен архив, музей, китапханәләрнең патриотик тәрбия бирү буенча материаллар әзерләү өчен мәгълүмат ресурслары белән тәэмин итү.

**6. Патриотик тәрбиядә дәүләт символларын куллану**

- Мәгариф учреждениеләрен, мәдәният учреждениеләрен, иҗтимагый оешмаларны Россия, Татарстан Республикасының

дәүләт символлары төшерелгән полиграфия продукциясе белән тәэмин итү
- дәүләт символларын кулланып, гражданнарны патриотик тәрбияләү мәсьәләләре буенча конкурслар, семинарлар, конференцияләр, күргәзмәләр үткәрү
- белем бирү учреждениеләрендә Россия һәм Татарстан Республикасы дәүләт символикасын, Дәүләт флагын, гербын һәм гимнын рәсми файдалану тәртибен өйрәнүне оештыру

## ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕ КРИТЕРИЙЛАРЫ

***Әхлакый-рухи күрсәткечләр:***
- яшьләр арасында толерантлыкны арттыру, экстремизм дәрәҗәсен киметү;
- Татарстан Республикасы һәм Ютазы муниципаль районы территориясендә яшәүче халыкларның бердәмлеген һәм дуслыгын саклау һәм ныгыту;
- яшьләрнең Ватанны саклауга әзерлеге;
- яшьләрнең республиканың соцяиаль-икътисади үсешендә кызыксынуы һәм аларның бу процесста катнашырга әзерлеге;
- массакүләм мәгълүмат чараларында патриотик тематиканы киңәйтү.

**Исәп параметрлары:**
- патриотик юнәлештәге үзәк буларак гамәлдәге балалар һәм яшьләр берләшмәләре исәбе;
- сәламәтләндерү һәм мәктәп яны лагерьларының хәрби-спорт профильле сменалары саны;
- патриотик берләшмәләрдә торучы балалар һәм яшьләр саны;
- патриотик юнәлештәге чараларда катнашучы балалар һәм яшьләрне колачлау.

## ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

Программаны гамәлгә ашыру механизмы тәрбия процессына йогынты ясауны тәэмин итү, массакүләм мәгълүмат чараларында патриотлыкны пропагандалау, иҗтимагый оешмаларны, берләшмәләрне берләштерү, аларның эшчәнлеген координацияләү максатында барлык дәрәҗәләрдәге муниципаль хакимият институтлары эше методларын камилләштерүгә нигезләнә.

## ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ

Программа чаралары район бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, максатчан чаралар һәм ирекле иганә акчасы хисабына тормышка ашырыла.

Программаны гамәлгә ашыру барышында аерым чаралар төгәлләнү белән бәйле рәвештә чараларны финанслау күләме җирле бюджетның расланган чыгымнарын исәпкә алып анықланачак һәм төзәтмәләр кертелергә тиеш булачак.

## ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДАН КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

Яшь буында патриотик тәрбия бирүнең Россия, Татарстан Республикасы, районның тарихи кыйммәтләре нигезендә югары мәдәният, патриотик хисләр һәм аң формалаштырырга мөмкинлек бирә торган тулы бер системасын булдыру.

Яшь буында Ватанга мәхәббәт, гражданлык бурычын һәм конституцион бурычларын җаваплы аңлау тәрбияләү.

Патриотик юнәлештәге яшүсмерләр клублары, кадет сыйныфлары булдыру.

Бала һәм яшүсмер шәхесен әхлакый, интеллектуаль һәм физик яктан формалаштыру өчен уңайлы шартлар тудыру.

Яшь буынны патриотик һәм гражданлык тәрбияләүдә бистәнең, авылларның гаиләләренә, иҗтимагый оешмаларына адреслы гамәли ярдәм күрсәтү.

Толерантлыкны көчәйтү, җәмгыятьтә идеологик каршылык дәрәҗәсен киметү.

Халыклар дуслыгы һәм бердәмлеген ныгыту.

Гражданнарның икътисад үсешендә кызыксынуларын тәэмин итү, җәмгыятьтә социаль киеренкелекне киметү.

Гражданнарның Ватанны саклауга әзерлегенә дөньяви караш формалаштыру.

Районда программаны тормышка ашыруның соңгы нәтиҗәсе булып патриотлык һәм интернационализм үсешенең уңай динамикасы, җәмгыятьтә рухи һәм мәдәни күтәрелеш өчен уңай шартлар тудыру, икътисади тотрыклылыкны ныгыту торырга тиеш.

Кушымта №2

Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
«__» _____ 2018 № ____

## ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ ПЛАНЫ

| т/б № | Чараның исеме | Уздыру сроклары | Җаваплы башкаручы | Финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| ***Бурыч 1: Оештыру чаралары*** | | | | **2018 ел** | **2019ел** | **2020 ел** |
| **1** | Балаларны һәм яшьләрне тәрбияләү буенча координация советы оештыру | 2018-2020 еллар | Башкарма комитет | - | - | - |
| **2** | Мәгариф учреждениеләрендә патриотик тәрбия торышы мониторингы | Даими | Координацион совет | - | - | - |
| **3** | Мәгариф учреждениеләрендә ветераннарга һәм барлык сугышларда, шулай ук барлык кораллы конфликтларда катнашучыларга ярдәм күрсәтү, һәйкәлләрне һәм обелискларны карап тоту буенча волонтерлык хәрәкәтен оештыру | Даими | «Мәгариф бүлеге" МКУ, белем бирү учреждениеләре | - | - | - |

***Бурыч 2: Балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча район массакүләм чаралары системасын үстерүне тәэмин итү***

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | Бөек Ватан сугышында җиңүнең 70 еллыгын бәйрәм итүгә хәзерләнү һәм аны уздыру буенча район Башлыгы карары белән расланган чараларны үтәү | Аерым план буенча | Координацион Совет | Аерым план һәм смета буенча | | |
| 5 | Тантаналы церемонияләр уздыру өчен мәгариф учреждениеләренең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы символикасы белән тәэмин ителеше | 2018-2020 еллар даими | «Мәгариф бүлеге" МКУ, белем бирү учреждениеләре | - | 30,0 | - |
| 6 | "Без – Россия гражданнары" – тантаналы рәвештә паспортлар тапшыру | 2018-2020 еллар | Балаларга естәмә белем бирүнең «Балалар иҗаты үзәге" МББУ, «Мәдәният бүлеге» МКУ | Аерым план һәм смета буенча | | |
| 7 | "Аҗаган", "Исән калу мәктәбе" хәрби-патриотик уеннары оештыру | 2018-2020 еллар | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ | 15,0<br>15,0 | 15,0<br>15,0 | 16,0<br>16,0 |
| 8 | Республиканың "Хәтер вахтасы" чараларында катнашуны тәэмин | 2018-2020 еллар | МКУ «Мәгариф бүлеге", белем бирү учреждениеләре, «Форпост» МБУ | - | - | - |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | буенча) | | | | | |
| 9 | Гомуми белем бирү мәктәпләрендә Беек Ватан сугышында катнашучылар, Әфган һәм Чечен конфликтлары, башка хәрби хәрәкәтләр ветераннары белән очрашулар уздыру | 2018-2020 еллар | «Мәгариф бүлеге” МКУ, белем бирү учреждениеләре | - | - | - |
| 0 | Чакырылышка кадәр яшьләр арасында хәрби-гамәли күп төр ярыш буенча район ярышларын уздыру | 2018 2020 еллар 23 февраль | «Форпост» МБУ | 4,9 | 5,7 | 8,0 |
| 1 | Мәктәп укучылары, авыл җирлекләре һәм сәнәгать предприятиеләре арасында спорт терләре буенча район Спартакиадасы ярышлары уздыру | 2018 - 2020 еллар | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ | 12,0 | 12,0 | 12,0 |
| 2 | Җиңү көненә багышланган җиңел атлетика буенча ярышлар – “Дан варислары” | 2018-2020 еллар, 9 май | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге” МКУ | 7,5 | 8,5 | 9,5 |
| 3 | Патриотик җыр һәм строй фестивален уздыру | 2018-2020 еллар | Балаларга естәмә белем бирүнең Балалар иҗаты үзәге” МББУ | 4,5 | 5,0 | 5,5 |
| 4 | «Ватанның тугры уллары” патриотик кино сеансларын оештыру | 2018-2020 еллар | «Мәдәният бүлеге” МКУ, киновидеочелтәр | - | - | - |
| 5 | “Әфган кискен | 2018-2020 | «Яшьләр эшләре, | 5,0 | 6,0 | 7,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | чарасын уздыру | еллар, февраль | спорт һәм туризм бүлеге" МКУ социаль яклау бүлеге | | | |
| 6 | Әфганстаннан гаскәрләрне чыгару еллыгына багышланган билбау көрәше буенча ярышлар уздыру | 2018-2020 еллар, февраль | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ | 11,3 | 12,3 | 13,3 |
| 7 | Хәрби комиссариат бүлеге белән берлектә "Призывник көне" уздыру | 2018-2020 еллар Язын һәм көзен | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге" МКУ | 66,2 | 68,2 | 70,2 |
| 8 | Мәгариф учреждениеләренең 10 сыйныф укучы-егетләре өчен биш көнлек өйрәнү җыеннары оештыру һәм уздыру | 2018-2020 еллар, май | «Мәгариф бүлеге» МКУ, белем бирү учреждениеләре | 50,0 | 55,0 | 60,0 |
| 9 | Патриотик, спорт, тарихи һәм төбәкне өйрәнү юнәлешендәге профильле сменалар һәм палатка лагерьлары эшен оештыру | 2018-2020 еллар | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, "Район мәгариф бүлеге" МКУ | Аерым план һәм смета буенча | | |
| 20 | Җәмәгать тәртибен саклау буенча "ФОРПОСТ" яшьләр (студентлар) формированиеләренең чараларын оештыру һәм үткәрү | 2018-2020 еллар | «Форпост» | Аерым план һәм смета буенча | | |
| 21 | Җиңү көненә велоузышлар уздыру | 2018-2020 еллар | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм | 23,0 | 24,0 | 25,0 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | бүлеге» МКУ | | | |
| 22 | Ватанны саклаучылар көненә багышланган массакүләм оборона эше айлыгы үткәрү | 2018-2020 еллар, май | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, “Район мәгариф бүлеге” МКУ | - | - | - |
| 23 | Беек Ватан сугышында Җиңү бәйрәменә багышланган төрле еллардагы сувенир продукциясе күргәзмәсен оештыру | 2018-2020 еллар, апрель | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, “Район мәгариф бүлеге” МКУ | 7,0 | 8,0 | 9,0 |
| 24 | Туган тебәкне өйрәнүгә багышланган туристик слетлар уздыру | 2018-2020 еллар, май | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, “Район мәгариф бүлеге” МКУ | 15,0 | 15,0 | 15,0 |
| 25 | «Очрашу урыны – Ютазы муниципаль районы» яшьләр слетларын уздыру | 2018-2020 еллар | «Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ | 17,0 | 18,0 | 20,0 |
| 26 | Һәйкәлләр һәм обелискларны төзекләндерү һәм җыештыру | 2018-2020 еллар | Барлык учреждениеләр | Аерым план һәм смета буенча | | |
| 27 | 1941-1945 еллардагы Беек Ватан сугышында җиңү кенена багышланган митинг-реквием, ветераннарны хөрмәтләү тантаналы парады уздыру һәм “Мәңгелек ут” хәтер мемориалы янына | 2018-2020 еллар, май | Барлык учреждениеләр | Аерым план һәм смета буенча | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 28 | “Район мәгариф учреждениеләрендә патриотик тәрбия” темасына фәнни - гамәли конференция уздыру | 2019 ел март | «Мәгариф бүлеге” МКУ, белем бирү учреждениеләре | 8,0 | 9,0 | 10,0 |
| 29 | Мәгариф учреждениеләрендә, предприятиеләрдә һәм авыл җирлекләрендә сугышчан дан почмакларын оештыру һәм аларның эше буенча конкурс үткәрү | 2014 елдан башлап, даими | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, “Район мәгариф бүлеге” МКУ | 9,0 | 10,0 | 11,0 |
| 30 | Муниципаль мәгариф учреждениеләре музейлары җитәкчеләренең район семинарын уздыру | 2019 ел | «Мәдәният бүлеге” МКУ | - | - | - |
| 31 | Патриотик тәрбия буенча педагогларның әзерлек дәрәҗәсен күтәрү (курслар, семинарлар, конференцияләр, мастер-класслар) | Программаның гамәлдә булу чорында | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге» МКУ, “Район мәгариф бүлеге” МКУ | 5,6 | 6,6 | 7,6 |
| 32 | Яшьләрне хәрби белгечлекләргә өйрәтүне оештыру | Ел саен | Хәрби комиссариат бүлеге, халык мәшгульлеге үзәге | Финанслау – заявкага ярашлы | Финанслау – заявкага ярашлы | Финанслау – заявкага ярашлы |

***Бурыч 4: Патриотик тәрбияне үстерүдә мәгълүмати-пропагандистик эшчәнлекнең, җирле массакүләм***

***... чаралары потенциалын файдалануның, мәгълүмати-коммуникацион технологияләр кулланунның нәтиҗәлелеген күтәрү***

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 33 | “Ютазы таңы” газетасында патриотик тәрбия һәм армиядә хәрби хезмәт турында даими рубрика оештыру | Даими | редакция | - | - | - |
| 34 | Район балаларын һәм яшьләрен патриотик тәрбияләү елкәсендә материалларны һәм нәтиҗәле эш формаларын гомумиләштерү һәм тарату | 2018-2020 еллар | «Мәгариф бүлеге” МКУ, белем бирү учреждениеләре | 5,0 | 5,0 | 5,0 |
| 35 | Ютазы районы бүлеге сайтында программаны гамәлгә ашыруны мәгълүмати чагылдыру | 2018-2020 еллар | Гомуми бүлек | - | - | - |
| 36 | “Батырлык дәресләре” кино атнасы | 2018-2020 еллар, 1-9 май | МКУ «Мәдәният бүлеге”, киновидеочелтәр | - | - | - |
| | | | | 386,9 | 443,0 | 426,1 |
| | **Барлыгы** | | | **1256,00** | | |

Кушымта №5
Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
«___» ______ 2018 № ______

**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында балаларны һәм яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча ведомствоара комиссия**
**СОСТАВЫ**

Самонина Светлана Петровна – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты рәисе - рәис;
Пройдакова Светлана Валерьевна - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль сораулар буенча урынбасары – рәиснең беренче урынбасары;
Хисмәтуллин Артур Айрат улы - яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге начальнигы – комиссия рәисе урынбасары;
Нигъмәтуллин Тимур Илдус улы – «Форпост» директоры - комиссия секретаре;

**Комиссия әгъзалары:**
Галиәхмәтова Гелнара Әнәс кызы – социаль яклау бүлеге начальнигы вазифаларын башкаручы (килешү буенча);
Воробьев Олег Леонидович – Ютазы РОСТО ДОСААФ рәисе (килешү буенча);
Крюкова Елена Валерьевна – “Ютазы таңы” район газетасының баш мөхәррире (килешү буенча);
Глушкова Зоя Васильевна – район ветераннар советы рәисе (килешү буенча);
Миңневәлиев Наил Назиф улы – «Халык мәшгульлеге үзәге” ДБУ директоры (килешү буенча);
Мөхәммәтова Руфия Габделмәҗит кызы – Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);
Орехов Всеволод Михайлович – призыв комиссиясе әгъзасы;
Гыйлаҗева Гүзәл Миңнеяр кызы – Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге начальнигы;
Сибәгатов Марат Вячеславович – Ютазы районы эчке эшләр бүлеге начальнигы (килешү буенча);
Шакирова Светлана Закир кызы – Ютазы муниципаль районы Үзәк район хастаханәсенең баш табибәсе (килешү буенча);
Халитов Илшат Назим улы – ТРның Баулы шәһәре, Баулы һәм Ютазы районнары буенча Хәрби комиссариат бүлеге начальнигы (килешү буенча);
Хәсәенова Алсу Наил кызы - Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы;